СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » май 2022 ел** **№ 48**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турында нигезләмәне раслау хакында» Иске Кырлай Советының 2021 елның 22 июнендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Иске Кырлай» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турында нигезләмәне раслау хакында» Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 22 июнендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 11 пунктны үз көчен югалткан дип санарга;

2) 16 пунктта «музейлар һәм китапханәләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ